**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Вәрәшбаш авыл җирлегенә керүче Вәрәшбаш авылы**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **10.12.2019 ел**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Вәрәшбаш авыл җирлеге составына керүче Вәрәшбаш торак пунктында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенә керүче Вәрәшбаш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

**1.** Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иске Вәрәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елга 1000 (бер мең) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500(биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Вәрәшбаш авылында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
- физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, Вәрәшбаш авылында рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;
- Вәрәшбаш авылында рәсми һәм мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыру
- Вәрәшбаш авылы территориясен төзекләндерүне оештыру;
- Вәрәшбаш авылы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;
- Вәрәшбаш авылында ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- Вәрәшбаш торак пункты чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү;
- Вәрәшбаш торак пункты чикләрендә юл эшчәнлеге;
- Вәрәшбаш авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру;
- җирлекнең территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;

- Вәрәшбаш т. п. территориясендә күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тору буенча чараларны гамәлгә ашыруга.

**3.** Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Вәрәшбаш авылы, Кооператив урамы, 45а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

**4.** Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Вәрәшбаш авыл җирлеге башлыгы** **З.М.Маннапова**